Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Иске Роман авыл җирлеге Советы
карары

2021 елның 28 апреле № 8/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84 - 86 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба текст буенча - Җирлек).»;

1.2. 6 статьяда:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:»;

1 пунктта түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктчалар өстәргә:

«17) участок вәкаләтле полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына әлеге вазыйфаны хезмәткәр биләгән вакытка торак урыны бирү;

18) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

1.3. 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12.1 пункт өстәргә:

«12.1) инициативалы проектлар;»;

1.4. 16 статьяда:

9 пунктта түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) инициативалы проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;

түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

«10.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициативалы проектны тәкъдим итә ала.»;

1.5. 20 статьяда:

1 пунктта «һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре турында,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1. Инициативалы проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

1.6. 22 статьяда:

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча өстәргә:

«2.1) торак пункт территориясенең составына керүче торак пункт территориясе өлешендә Татарстан Республикасы законы нигезендә, торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;»;

4 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге статьяның 3 пунктындагы 2.1 пунктчасында каралган гражданнарның җыены, торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче кимендә 10 кеше төркеме инициативасы белән, Җирлек Советы тарафыннан чакырылырга мөмкин.

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин булган җирлек составына керүче торак пункт территориясенең бер өлешенең чикләрен билгеләү критерийлары Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

9 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең өлешләре)» сүзләрен өстәргә;

1.7. 23 статьяда:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сораштыруда муниципаль берәмлек халкы яисә аның бер өлеше уналты яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.»;

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) уналты яшькә җиткән кешеләрнең инициативалы проектын гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлектә яшәүчеләрнең яисә аның өлешләренең - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

5 пунктта:

беренче абзацта «Җирлек Советы тарафыннан. Карарда» сүзләрен «Җирлек Советы тарафыннан. Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кулланылырга мөмкин. Карарда» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

7 пунктның 1 пунктчасында «яисә муниципаль берәмлек халкы» сүзләрен өстәргә;

1.8. 28 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру өчен, аена ике эш көне чорына эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.»;

1.9. 76 статьяда:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Җирлек бюджеты Җирлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен билгеләнгән.»;

3-4 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.10. 77 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, Җирлектә бюджет процессын мөстәкыйль гамәлгә ашыралар. Җирлектә бюджет процессы турындагы нигезләмә җирлек Советының муниципаль хокукый акты белән раслана.»;

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирле үзидарә органнары Җирлектә яшәүчеләргә аларны бастырып чыгару мөмкин булмаган очракта күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр белән танышу мөмкинлеген тәэмин итә.»;

3-4 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җирлек бюджеты проектын төзү тәртибе, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Җирлектә Бюджет процессы турындагы нигезләмә белән билгеләнгән таләпләрне үтәп, Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә»;

7-9, 15-19 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.11. 79 статьяда:

1 пунктта «торак пункт» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең өлешләре)» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «4.1 пунктында» сүзләрен «4.1 һәм 4.3 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

1.12. 80 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек муниципаль бурыч алуларны, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чыгару юлы белән дә гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.13. 81 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек бюджетын үтәү Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.»;

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.14. 82 статьяда:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«82 статья. Бюджет хисабы. Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап»;

1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап квартал саен исәпләнә.»;

2 пунктта «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тәкъдим итү, карау һәм раслау тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә Җирлек советы тарафыннан билгеләнә.»;

4 пунктның 1 абзацында «тапшыру» сүзен «карау» сүзенә алмаштырырга;

5 пунктта «, бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисабының тышкы тикшерүе күрсәткечләре нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык отчет агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча Җирлек Советына тапшырыла.

Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта аңа аңлатма язуы, ул Җирлек бюджетының һәм бюджет хисаплылыгының үтәлеше анализын үз эченә алган, муниципаль йөкләмәнең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр, бюджет үтәлеше турында карар проекты, Җирлек бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгы һәм берләштерелгән бюджет үтәлеше турында бюджет хисаплылыгы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла.»;

8 пунктта:

1 абзацта «йә еллык хисапны кире кагу» сүзләрен «йә карарны кире кагу» сүзләренә алмаштырырга;

2 абзацта «еллык хисап» сүзләрен «карар» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта 2-6 абзацларны төшереп калдырырга;

1.15. 83 статьяда:

1 пунктта «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары» сүзләрен «Җирлек бюджеты» сүзләренә алмаштырырга;

2, 5-6 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

86 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «аның» сүзен төшереп калдырырга, «Муниципаль берәмлекләр уставын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында Җирлек уставы, муниципаль хокукый акт турында белешмәләр кертү хакында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар, әлеге карар үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның 1.16 пункты 2021 елның 7 июненнән үз көченә керә.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г. Дәүләтшина